**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№899**
**24.02.2022**

Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» МАУга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт статусы бирү турында

Җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру максатларында, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 23 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясындагы 9 пунктының 13 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» муниципаль автономияле учреждениесенә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтүче җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт статусы бирергә.
2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтүче җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеген оештыру турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.
3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.Н. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 24 февралендәге
899 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтүче
җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт
эшчәнлеген оештыру турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтүче җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт (алга таба – махсуслаштырылган хезмәт) Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә муниципаль автономияле учреждение рәвешендә төзелә.

Махсуслаштырылган хезмәт статусы элек төзелгән муниципаль учреждениегә бирелергә мөмкин. Муниципаль учреждениегә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт статусы бирү турындагы карар Башкарма комитет тарафыннан кабул ителә.

2. Махсуслаштырылган хезмәт үз эшчәнлегендә «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Президентының «Гражданнарның вафат булган кешеләрне җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүгә хокуклары гарантияләре турында» 1996 елның 29 июнендәге 1001 номерлы Указы, «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эшен оештыру турында» 2017 елның 21 апрелендәге 2465 номерлы карары һәм башка муниципаль хокукый актларга таяна.

2 бүлек. Махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләре

3. Махсуслаштырылган хезмәт әлеге нигезләмәдә билгеләнгән таләпләр нигезендә, вафат булган гражданнарны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге җәмәгать зиратларында җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтә. Вафат булган кешенең иренә (хатынына), якын туганнарына, башка туганнарына, законлы вәкилгә яки аны җирләүне гамәлгә ашыру бурычын үз өстенә алган башка затка җирләү буенча түбәндәге исемлек нигезендә түләүсез хезмәтләр күрсәтү гарантияләнә:

1) җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;

2) табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү;

3) вафат булган кешенең гәүдәсен (мәетне) зиратка илтү;

4) җирләү.

Җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча тиешле бүлекчәләре, Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты белән килештереп, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

4. Вафат булган кешенең ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары яисә законлы вәкиле булмаганда яки алар тарафыннан җирләүне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда, шулай ук җирләүне гамәлгә ашыру бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда, Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, өйдә, урамда яки башка урында вафат булган кешене җирләү, эчке эшләр органнары тарафыннан аның шәхесе билгеләнгәннән соң, үлем сәбәбе билгеләнгән вакыттан башлап өч тәүлек эчендә махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда эчке эшләр органнары тарафыннан шәхесе билгеләнмәгән вафат булган кешеләрне җирләү, әлеге органнарның ризалыгы буенча, җәмәгать зиратларының мондый очраклар өчен билгеләнгән участокларында җиргә иңдерү юлы белән махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6. Әлеге нигезләмәнең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән вафат булган кешеләрне җирләгәндә махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;
2) мәетне төрү;
3) табут бирү;
4) вафат булган кешене зиратка илтү;
5) җирләү.

Күрсәтелгән хезмәтләрнең бәясе «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пунктында каралган тәртиптә Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

7. Вафат булган кешене җирләүне үз өстенә алган затның теләге буенча махсуслаштырылган хезмәт, җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегеннән тыш, түләүле нигездә хезмәт күрсәтергә мөмкин.

8. Махсуслаштырылган хезмәт җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтү турында гариза (әлеге Тәртипкә кушымта) кабул итүне гамәлгә ашыра. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

- үлү турында белешмәнең төп нөсхәсе (11 нче форма);
- үлү турында таныклык күчермәсе;
- вафат булган кешенең паспорт күчермәсе;
- гариза бирүченең паспорт күчермәсе.

## 3 бүлек. Махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеген оештыруга таләпләр

9. Махсуслаштырылган хезмәт күмү һәм җирләү эше өлкәсендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәргә тиеш, шул исәптән:

- түләүсез нигездә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре;
- җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә керүче хезмәтләр күрсәтү сыйфатына карата таләпләр.

Махсуслаштырылган хезмәт җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча заказлар кабул итү һәм үтәү буенча документларның архив фондын формалаштыруны тәэмин итә.

10. Кирәкле акчалар булмау яки башка сәбәпләр буенча, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтнең гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтүдән баш тартуы рөхсәт ителми.

11. Махсуслаштырылган хезмәт хокуклы түгел:

1) вафат булган кешенең теләгән гамәлгә ашыручы, шулай ук вафат булган кешенең ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары, законлы вәкилләре, вафат булган кешене җирләүне гамәлгә ашыру бурычларын үз өстенә алган башка затлар исеменнән һәм аларның кушуы буенча эш итүче затларга җирләүне (шул исәптән вафат булган кешене җиргә иңдерү юлы белән) гамәлгә ашыруда каршылык күрсәтергә;

2) махсуслаштырылган хезмәттән ритуаль хезмәтләр, шул исәптән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә керә торган хезмәтләрне түләүле нигездә сатып алуны мәҗбүр итәргә (ирексезләп кушарга).

4 бүлек. Махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибенә төп таләпләр

12. Җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтүгә заказ кабул итү, мөрәҗәгать иткән көнне махсуслаштырылган хезмәт заказларын кабул итү урыны буенча махсуслаштырылган хезмәт хезмәткәре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

13. Махсуслаштырылган хезмәт хезмәткәре махсуслаштырылган хезмәткә мөрәҗәгать иткән затка консультация ярдәме күрсәтә:

- җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтү тәртибе буенча;
- зиратларның эш кагыйдәләре буенча;
- күмү һәм җирләү эше өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә гражданнарга түләнә торган бер тапкыр бирелүче матди ярдәм һәм җирләү өчен социаль пособие бирү тәртибе һәм күләмнәре буенча.

14. Махсуслаштырылган хезмәт хезмәткәре җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерә, гореф-гадәтләр һәм традицияләр, шулай ук вафат булган кешенең дине буенча, җирләү датасын һәм вакытын билгели.

Документларны рәсмиләштерү нәтиҗәләре буенча махсуслаштырылган хезмәт әлеге нигезләмәнең 2 бүлеге нигезендә җирләү буенча хезмәт күрсәтә.

15. Махсуслаштырылган хезмәт түбәндәгеләргә ия булырга тиеш:

1) җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтүгә заказлар кабул итүнең тиешле шартларын тәэмин итә торган милек, аренда хокукындагы яисә башка законлы нигездә махсус җиһазландырылган биналар;

2) хезмәтләр күрсәтү өчен махсуслаштырылган транспорт;

3) хезмәтләр күрсәтү өчен персонал;

4) туры телефон элемтәсе булу;

5) түбәндәге мәгълүмат булган элмә такта: оешманың исеме, аның урнашу урыны (юридик адресы), шулай ук эш режимы.

16. Җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтүгә заказлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган махсуслаштырылган хезмәт бинасында, карау мөмкинлеге булган урында түбәндәге мәҗбүри мәгълүмат булырга тиеш:

1) «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон;

2) Россия Федерациясе Президентының «Гражданнарның вафат булган кешеләрне җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүгә хокуклары гарантияләре турында» 1996 елның 29 июнендәге 1001 номерлы Указы;

3) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

4) җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге;

5) җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган җирләү билгеләнешендә әзерләнә һәм реализацияләнә торган предметларның үрнәкләре (модельләре) яисә аларның фотографияләре;

6) җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегеннән тыш күрсәтелә һәм бирелә торган ритуаль хезмәтләргә һәм ритуаль билгеләнештәге предметларга прейскурант;

7) җирләгәндә файдаланыла торган предметлар һәм әйберләр (табутлар, веноклар, кабер ташлары һ.б.) турында  санитар-эпидемиологик бәяләмәләр (алар ктрәк булган очракта) булу турында мәгълүматлар;

8) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту тәртибе (2017 елның 21 апрелендәге 2465 номерлы карар белән расланган).

5 бүлек. Махсуслаштырылган хезмәтнең җаваплылыгы

17. Күмү һәм җирләү эше өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен махсуслаштырылган хезмәт гамәлдәге законнар нигезендә җавап бирә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтүче җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеген оештыру турында нигезләмәгә кушымта

Махсуслаштырылган хезмәт җитәкчесе

___________________________________

кемнән ___________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

түбәндәге адрес буенча яшәүче:

___________________________________

тел. ______________________________

гариза.

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, Сездән вафат булган кешене җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтүегезне сорыйм:

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

туу датасы: ___________________________

үлү датасы: ___________________________

түбәндәге адрес буенча теркәлгән: ___________________________________________

___________________________________________________________________________.

Кушымта:

1) үлү турында таныклык күчермәсе
№ ________________________________________________;
2) үлү турындагы белешмәнең төп нөсхәсе (11 нче форма) _____________ _____________;
3) вафат булган кешенең паспорт күчермәсе;
4) гариза бирүченең паспорт күчермәсе.

Гариза бирүче ______________________ ______________________________
(имза) (дата)

Җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә хезмәтләрдән файдаланган гражданнарга җирләү өчен 8-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясында каралган социаль пособие түләнмәү турында белдерелде.

Гариза бирүче ______________________ _ ______________________________
(имза) (дата)

Заказлар кабул итүче: __________________________ Җирләү датасы ______________________
(Ф.И.А.и.)